# Татар телендә урта гомуми белем бирү мәктәбенең
# 7 нче сыйныфында укучы татар балалары өчен
# татар теленнән үткәрелә торган республика олимпиадасының
# муниципаль этабы өчен биремнәр
# (2014/2015 нче уку елы)

**I. Тестлардан берәр дөрес җавапны билгеләгез.**

1. Татар язуы тарихы кайсы төркемдә дөрес күрсәтелгән?
   а) гарәп → латин → кириллица → латин;
   ә) рун → уйгыр → гарәп → латин → кириллица;
   б) рун → уйгыр → латин → гарәп → кириллица;
   в) уйгыр → рун → гарәп → латин → кириллица.

2. Сингармонизм законы сакланмаган сүзләр рәтен күрсәтегез.
   а) ишектәге, караңгыда, язмыш;
   ә) кешелек, әнкәй, имәндәй;
   б) китаптан, зәңгәрсу, тарихи;
   в) алдынгы, акыллы, йөгерде.

3. Иҗек калыбы ялгыш күрсәтелгән сүзне табыгыз.
   а) ТСТ – ТС – ТСТ – көнкүреш;
   ә) ТСТ – ТСТ – ТС – дүртенче;
   б) ТСТ – ТС – койма;
   в) ТС – ТСТ –СТ – ябалак.

4. Нигезе ялгыш билгеләнгән сүзләр рәтен билгеләгез.
   а) тырышлык-ка ялкынлы -рак, иртә-дән;
   ә) тимерчелек-тә, урман-нан, төньяк-тан;
   б) белер-сең, киемнәр-ең, әйт-елгәнчә;
   в) бала-кай, сүзлек-тә, эшлекле.

5. *Кояш, нәкъ аңа карап, алтын нурларын коя* җөмләсендә күчерелмә мәгънәдә кулланылган сүз -
   а) кояш,
   ә) нурларын;
   б) коя;
   в) аңа.

6. Фразеологик берәмлекләр кергән рәтне күрсәтегез.
   а) күгәрчен күзе, үги ана яфрагы, җир җиләге;
   ә) баш вату, авызга су кабу, теш кайрау;
   б) иртә-кич, эреле-ваклы, балта кайрау;
   в) бала уенчыгы, алтын беләзек, бәбкә үләне.

7. Тартык авазларның үзара охшашлануы
   а) сингармонизм;
   ә) аккомодация;
   б) ассимиляция;
   в) орфоэпия дип атала

8. Күчерелмә мәгънәле сүзләр рәтен күрсәтегез.
   а) җылы кич, кунак килә, учак яну;
   ә) кайнар хис, җылы караш, ак бәхет;
   б) кеше килә, ак чәчәк, кайнар су;
   в) кунак апа, җылы бүлмә, матур кыз.

9. Кайсы рәттәге сүздә тамыр дөрес күрсәтелмәгән?
   а) бүлмә (бүл-);
   ә) ямьсезләнү (ямьсез-);
   б) борылмалы (бор-);
   в) тамырдаш (тамыр-).

10. Кайсы рәттә *безнекеләрнең* сүзе мәгънәле кисәкләргә дөрес бүленгән?
   а) без-не-ке-ләр-нең;
   ә) безнеке-ләр-нең;
   б) без-неке-ләр-нең;
   в) без-неке-ләрнең.

11. Кайсы рәттә сүз ясагыч кушымчалар бирелгән?
   а) -да/-дә, -ым/-ем, -нан/-нән;
   ә) -ырга/-ергә, -ны/-не, -рак/-рәк;
   б) -гач/-гәч, -ып/-еп, -ганчы/-гәнче;
   в) -лы/-ле, -даш/-дәш, -чы/че.

12. Мәгънәдәш сүзләргә нигезләнеп ясалган парлы сүзләр төркемен билгеләгез.
   а) ачлы-туклы, алдым-бирдем, килде-китте;
   ә) берәм-сәрәм, аз-маз, савыт-саба;
   б) дус-иш, явым-төшем, кирәк-ярак;
   в) ул-бу, берәм-берәм, икәүдән-икәү.

13. *Үз* алмашлыгы кайсы төркемчәгә керә?
   а) күрсәтү;
   ә) билгеләү;
   б) тартым;
   в) зат.

14. Грамматик категорияләргә иң бай булган сүз төркеме –
   а) исем;
   ә) алмашлык;
   б) фигыль;
   в) сыйфат.

15. Сыйфат фигыльнең барлыгы ничә формасы бар?
   а) 5;
   ә) 6;
   б) 4;
   в) 7.

16. Аваз ияртемнәре ...
   а) модаль сүз төркемнәренә;
   ә) бәйләгеч сүз төркемнәренә;
   б) мөстәкыйль сүз төркемнәренә;
   в) үзенчәлекле сүз төркемнәренә керә.

17. Фигыль сүзтезмәләрдән торган рәтне билгеләгез.
   а) тегүче апа, мәктәп бинасы, ләйсән яңгыр;
   ә) җәяү бару, эшне эшләп бетерү, укыгач белү;
   б) сыйныф бүлмәсе, өченче класс, аларның улы;
   в) уку китабы, язма эш, кояшлы алан.

18. Җөмләдә ачыклаулы мөнәсәбәттә булган ничә сүзтезмә бар?

*Ап-ак көмешкә әйләнгән яфраклары белән алар да суда коена башладылар*. (Г.Исхакый)

а) 5;
ә) 4;
б) 3;
в) 6.

19. Хәбәрлекле мөнәсәбәткә кергән сүзләр ...

а) җөмлә;
ә) сүзтезмә;
б) тезмә сүз;
в) синтагма төзиләр.

20. Җөмләдәге аерымланган хәлнең төрен билгеләгез.

*Бал кортлары, бер чәчәктән икенчесенә куна-куна, татлы нектар эчәләр*. (Ф.Яруллин)

а) сәбәп хәле;
ә) рәвеш хәле;
б) максат хәле;
в) вакыт хәле.

## II. Теоретик бирем.
## Әйтү максаты буенча җөмлә төрләре.

## III. Күп нокта907 урынына тиешле сүзләрне куегыз.

1. Кушма сүзләрнең икенче тамыры *я, ю, е* хәрефләренә башланганда, *ь, ъ* хәрефләре ... ... буларак языла. 2. Татар телендә ... яңгырау тартык, ... саңгырау тартык бар. 3. Төрле халыклар аралашу нәтиҗәсендә ... сүзләр барлыкка килә. 4. Лексикография – ... төзү турындагы фән ул. 5. Тамыр, нигез һәм кушымчалар сүзнең ... кисәкләре дип атала. 6. Сыйфатларның да, рәвешләрнең дә ... формалары була. 7. Предметның эшен билге итеп белдерә торган фигыль төркемчәсе ... фигыль була. 8. Саналмышы булмаган сан төркемчәсе ул – ... саны. 9. Сөйләм оештыру өчен, ... бәйләнешнең булуы шарт. 10. Ия белән хәбәр арасында ... мөнәсәбәт була.

## IV. Гамәли бирем.

*Татарстан яшел тугайлы болыннарга, куе әрәмәләргә, балыклы, кош-кортлы агым суларга, түгәрәк күлләргә бик бай.* (Г.Б.)

1. Җөмлә төрен билгеләргә.
2. Тыныш билгеләрен аңлатырга.
3. Җөмлә кисәкләре буенча (астына сызып) тикшерергә.
4. *Болын* сүзенә фонетик анализ ясарга.
5. *Кош-кортлы, Татарстан, бик* сүзләренә морфологик анализ ясарга.
6. *Әрәмәләргә* сүзен төзелеше һәм ясалышы ягыннан тикшерергә.